Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№37 (88)

21 ноябрь 2013 ел

## Вакыйгалар эзеннән

16 ноябрьдә Алабуга институтында укучылар һәм студентлар өчен IV Бөтенроссия **«ТАТАР ТЕЛЕ, ӘДӘБИЯТЫ** һәм **ТАРИХЫ: ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ, КИЛӘЧӘГЕ»** дип исемләнгән конференция узды. Чарада Башкортстан, Чувашия республикалары, Пермь өлкәсе вәкилләре дә катнашты. Анда барлыгы 9 секция эшләде. Укытучылар өчен «Хәзерге заманда белем алучыларның үсеш концепцияләре» исемле мастер-класс та үткәрелде.

• • • •

18 ноябрь көнне КФУда **DAAD** (Deutscher Akademischer Austausch Dienst) **ГЕРМАНИЯ АКАДЕМИК АЛМАШУ ХЕЗМӘТЕ СТИПЕНДИЯ ПРОГРАММАСЫ ТӘКЪДИР ИТЕЛДЕ**. Казандагы DAAD Мәгълүмати үзәк директоры Тило Цинеккер һәм аның хезмәттәше Мария Кулькова 2014-2015 уку елына РФ студентлары, аспирантлары һәм галимнәре өчен яңа грантлар хакында сөйләде.

• • • •

Шул ук көнне, Хабаровск краендагы су басудан зыян күрүчеләргә ярдәм йөзеннән, 4 **ТОННАЛЫК ГУМАНИТАР ЙӨК ТӨЯЛГӘН АВТОМОБИЛЬ КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ТӨП БИНАСЫ ЯНЫННАН КУЗГАЛДЫ**. Аны ректор **И.ГАФУРОВ** җитәкчелегендә КФУ һәм республикабызның башка вуз студентлары озатып җибәрде.

• • • •

19 ноябрь көнне КФУда ректор **И.ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Ул 17 ноябрьдә «Казан» Халыкара аэропортында авиаһәлакәттә һәлак булучыларны бер минут тынлык белән искә алудан башланды. Ректор бу атнаны буласы барлык күңел ачу чараларын кичектерергә дигән әмер бирде. 18 ноябрьдә буласы Университетның туган көненә багышланган концерт та шул сәбәпле башка вакытка күчерелде. Контроль йөкләмәләр үтәлеше белән административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** таныштырды. Икътисади һәм стратегик үсеш мәсьәләләре буенча проректор **М.САФИУЛЛИН** 2013-2020 еллар арасында дөньяда әйдәп бара торган фәнни-белем бирү үзәкләре арасында КФУның конкурентлылыгын арттыру программасын гамәлгә ашыру өчен башкарыласы эшләр турында сөйләде. Проректор КФУның «Юл картасын» яклаганда, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының Халыкара фәнни советы утырышы бәяләмәләре белән таныштырды. Ректор киңәшчесе – иҗтимагый-мәгълүмати үзәк җитәкчесе **Ю.АЛАЕВ** КФУ сайтын үстерү буенча башкарылган эшләр турында сөйләде. Аның сүзләренчә, «Яндекс новости» белән килешү төзү турында сөйләшүләр алып барыла. Ахырдан эчке режим, гражданлык оборонасы һәм хезмәт саклау департаменты җитәкчесе **А.ТАҖИЕВ** барлык структур бүлек җитәкчеләренә «Требования федерального и республиканского законодательства в области гражданской защиты и предупредительно-профилактическая работа по недопущению чрезвычайных ситуаций» семинарында катнашу кирәклеген искәртте. Әлеге чара кичә, ягъни 20 ноябрьдә, үтте.

• • • •

19 ноябрьдә Россия һәм яңа бәйсез дәүләтләр белән сәүдә эшләре буенча **ЯПОН АССОЦИАЦИЯСЕ КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ БЕЛӘН** берлектә **СЕМИНАР** үткәрде. Ул Казандагы Япония-Россия кара алтын һәм газ технологияләре темасына багышланды. Лекцияне «JGC» Япониядәге иң эре инжиниринг компаниясе белгечләре укыды. Чара рус һәм япон телләрендә барды.

• • • •

22-23 ноябрь көннәрендә юридик факультет базасында профессор М.Челышев истәлегенә багышланган **«ХОКУК ӨЛКӘСЕНДӘ СИСТЕМААРА ҺӘМ ТАРМАКАРА ЭЛЕМТӘЛӘР»** темасына студентлар һәм аспирантлар гамәли конференциясе үткәрелачәк. Аның максаты – комплексы һәм тармакара хокук мәсьәләләрен тәртипкә кертүнең перспектив үсеше турында фикер алышу, систематара һәм тармакара элемтәләрнең асылын билгеләү һәм тикшерү.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*



Влад Михневский фотосы

# Урбанистика серләрен өйрәнәбез!

Казан федераль университетына дөньяның төрле почмакларыннан галимнәр килә. Алар студентлар өчен кызыклы темаларга лекцияләр укый, тәҗрибәләрен уртаклаша. Шушы көннәрдә университетыбызга килгән Мексика галиме Мигель Робль-Дюран лекцияләрен дә студентлар кызыксынып тыңлады. Бу аның Казанга беренче тапкыр килүе. *Дәвамы 2 биттә.*

• Чара

# Очрашулар нәтиҗәле булсын!

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

18 ноябрь көнне Тарих музеенда КФУның студент оешмалары һәм берләшмәләре Координация советының киңәйтелгән утырышы булып узды.

Хәзерге заман белем бирү системасына таянган яшьләр сәясәте өлкәсендәге актуаль мәсьәләләр һәм эшчәнлек юнәлешенең үсеш перспективалары турында фикер алышуда Россиянең төрле уку йортлары, дәүләт һәм җәмәгать оешмалары да катнашты. Алар арасында: Н.П.Огарев ис. Мордовия дәүләт университеты, Төньяк Кавказ федераль университеты, Пенза дәүләт университеты, Л.Н.Толстой ис. Тула дәүләт педагогика университеты, Оренбург дәүләт педагогик университеты, Санкт-Петербург дәүләт политехника университеты, Казан шәһәре башкарма комитетының балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, «Буревестник» яшьләр физик тәрбия җәмгыяте, «ТР Яшьләр Лигасы» бар иде.

Утырышта дәрәҗәле кунаклар: РФ Дәүләт думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов, ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры урынбасары Рөстәм Гарифуллин, Казан шәһәре башкарма комитетының балалар һәм яшьләр эшләре комитеты рәисе урынбасары, яшьләр проектларының иҗади һәм имидж бүлеге мөдире Ирина Бочкова катнашты.

Чара «Патриотик тәрбия», «Студент спорты үсеше», «Иҗади инициативаларны тормышка ашыру», «Студент җәмгять оешмаларының эшчәнлеген оештыру» кебек блок-секцияләргә бүлеп алып барылды. Боларның һәркайсында югары уку йортлары һәм республика җәмәгать оешмалары лидерлары, хакимият вәкилләре актуаль проблемаларга, үсеш перспективаларына карата үз фикерләрен әйттеләр.

Утырышны тәрбия һәм социаль эшләр буенча проректор А.Межведилов ачып җибәрде. «Тәрбия – безнең университетта уку процессыннан алыштыргысыз өлеше. КФУ студентларның инициативаларын кабул итәргә һәрвакыт әзер», – дип белдерде проректор.

«Патриотик тәрбия» блогында биккызыклы фикерләр яңгырады. Әйтик, Тел институтының немец теле кафедрасы профессоры Фиана Ратнер: «Патриотизмга килгәндә, ил синең өчен нәрсә эшләде дип түгел, ә син ил өчен нәрсә эшләдең, дип сорарга кирәк. Патриотик тәрбия үгетнәсыйхәткә генә кайтып калырга тиеш түгел, ул, һичшиксез, гаиләдән башланырга тиеш. Җәмәгать активлыгы исә, кеше



Влад Михневский фотосы

һәм хакимият арасында ышаныч булганда гына бар. Шул вакытта гына кеше үз фикерен нинди дә булса әһәмиятkә ия дип беләчәк», – диде үз чыгышында.

Студентларның «Патриотик тәрбия үзәге» оешмасы 2011 елда гына ачылган. Максаты – хезмәт, эзләнү отрядларының файдалы эшчәнлеген берләштерү. Оешма җитәкчесе Рөстәм Абрахманов: «Мин очраткан иң мөһим проблемаларның берсе – студентларның җәмгыять өчен файдалы эшчәнлектә катнашмавы. Моны ничек хәл итәргә? Минемчә, студентлардан үз фикерен төгәл җиткерә алырлык кешеләр кергән агитбригадалар оештырырга кирәк. Студентлар белән уку йорты администрациясе түгел, ә студентлар эшләве мөһим. Бу нәтиҗәлерәк булыр иде», – диде.

«Студент спорты үсеше» блок-секциясендә Россиядә һәм төбәктә студент спорт клубларының, «ТР студентлар Лигасы», массакүләм спорт үсеше буенча КФУның спорт клубы, Универсиада авылындагы һәвәскәрләр спорты һ.б оешмаларның оешуы турында докладлар тыңланды.

Иҗади инициативаларны тормышка ашыру мәсьәләре турында сөйләшкәндә, катнашучылар аеруча активлашып китте. Монда Казан студентларының иҗади потенциалы үсеше, студентларны иҗади процесска кертеп җибәрү методлары, иҗади шәхес формалашу принциплары, студент клубларының өстенлек иткән юнәлешләре турында фикер алыштылар.

«Студентларның җәмгыять оешмалары эшчәнлеген оештыру» блок-секциясендә Россия вузлары вәкилләре университетларда үзләренең студент оешмаларын оештыру тәҗрибәсе турында сүз алып бардылар. КФУдан «Политсковородка» проектын Яна Сюрикова тәкъдим итте. КФУдагы студент оешмаларының эшләү формалары һәм үзара бәйләнеше темасын үз чыгышында Роберт Зиниятуллин яктыртты.

Депутат И.Гыйльметдиновның чыгышы студентлар һәм җәмгать оешмалары лидерлары өчен аеруча файдалы булды. Ул чыгышында студентлардан тулай торак өчен арттырылган бәя таләп итү яки бөтенләй урын бирелмәү проблемасын да әйтеп узды. «Кызганычка каршы, күпчелек төбәкләрдә, шул исәптән Мәскәү, Санкт-Петербургта, тулай торак өчен хәтта җиде мең түләргә кирәк. Бу – студентларны мыскыл итү! Универсиада авылындагы кебек, яшәү өчен шундый уңайлы шартлар тудырылган һәм аена 180 сум гына түләү билгеләнгән тулай торак Россиядә, гомумән, юк. Шуңа омтылырга кирәк. Без хәзер проблеманы хәл итүче законга үзгәртүләр әзерлибез».

Координация советы утырышы студентларның үзидарә системасы үсешендәге, югары профессиональ белем бирү модернизациясен тәэмин итүдәге һәм студент шәхесенең ролен үстерүдәге мөһим ролен билгеләүгә юнәлтелде. Россиянең студент оешмалары арасында тәҗрибә уртаклашу, һичшиксез, нәтиҗәсез калмас.

• Заман таләбе

# КФУ смартфоннарда!

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Казан федераль университеты составына бик күп факультет һәм институтлар керә. Аларның күбесе аерым уку биналарында урнашкан. Бүген ул биналарның саны берничә дистәгә якын. Кайвакыт хәтта 3-4 курста укучы студентлар да кайда кайсы институт урнашканын белми, адашып йөри. Бу проблема Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтында укучы студентларны да борчый башлаган.



Студентлар, әлеге проблеманы хәл итү максатыннан, ниндидер программа яки кушымта чыгару идеясе белән яна башлый. Башта бу эш бары тик курс эше буларак барса, алга таба ул, зур үсеш алып, житди проектка әйләнә. Күптән түгел әлеге проект тулы көченә эшли башлаган. Аның исеме «KFU Guide». Нинди проект соң ул, дигән сорау борчый башладымы? Җавап бирәбез – бу смартфоннар өчен ясалган кушымта. Аның ярдәмендә һәр кеше КФУның институтлары, факультетлары турында мәгълүмат таба ала, шулай ук, кушымтадан чыкмаган килеш, конкрет уку бинасында нәрсә урнашканын белергә мөмкин. Администрация белән элемтәгә керергә теләүчеләргә дә кушымта ярдәм итәчәк.

Иң кызыгы шул: әлеге проектны уйлап чыгаручылар – кызлар. Аларбөтенесе дә Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтының 5 курс студентлары. Илсөяр Алимова «KFU Guide» кушымтасын – Android, Екатерина Чернова – Windows Phone, ә Ирина Шахова iOS платформалары өчен уйлап чыгара. Әйтергә кирәк, әлеге платформалар бер-берсеннән шактый аерыла, шуңа күрә кызларга кушымтаның төрләрен аларның асылына туры китереп әзерләргә кирәк булган. «KFU Guide»ны смартфоннары булган кешеләрнең бушлай алу мөмкинлекләре бар. Мин дә, әлеге кушымтаны телефоныма урнаштырдым. Ул бик җайлы, аңлаешлы итеп ясалган. Һәр институтның, факультетның фактик һәм электрон адресы, телефон номеры, сайты язылган. Карта да бар.

Университет буенча күрсәткечне студент кызлар КФУның мәгълүмати технологияләр һәм системалар югары мәктәбе белән берлектә әзерләсәләр, кушымтаны чыгару эше белән КФУның «Ачык технологияләр лабораториясе» шөгыльләнгән.

«KFU Guide» хәзер тулы көченә эшли, ләкин уйлап табучылар алга таба аны тагын да камилләштерергә, яхшырак итәргә тели. Аларның планнары тормышка ашар дип өметләнәбез һәм уңышлар телибез.

• Бездә кунак бар

19 ноябрьдә Казан университетында шәһәр үсеше, урбанистика һәм территорияләрне стратегик планлаштыру буенча дөньяви белгеч Мигель Робль-Дюранның ачык лекцияләре башланды.

# Урбанистика серләрен өйрәнәбез!

**Дания ФАТЫЙХОВА**

Планлаштырылган барлык өч дәрес тә инглиз телендә үтте һәм алар рус теленә синхрон рәвештә тәрҗемә ителде.

Лекцияне тыңлаучылар галимнән үз тәҗрибәсенә таянып чыгыш ясавын сорадылар. Робль Дюран дәресләре дискуссион формада узды һәм, шул рәвешле, ул катнашучыларның да фикерләре белән танышып барды.

Мигель Робль-Дюран (1975) – Мексика архитекторы һәм урбанисты. Ул Роттердам һәм Нью-Йорк шәһәрләрендә «Бер-берсенә җайлашып яшәү стратегиясе» иҗтимагый-пространстволы үсеш кооперативына нигез салучыларның берсе булып тора. Әлеге оешма шәһәр вәзгыятендәге конфликтлар һәм модернизация мәсьәләләре белән бәйле стратегияләр үсеше һәм дизайнерлык интервенцияләре белән шөгыльләнә.

Робль-Дюран урбанистика һәм дизайн теориясе буенча күп университетларда (Ибероамерика университеты, Тихуана; Вудбери университеты, Лос-Анджелес/Сан-Диего; Левен Католик университеты, Левен; Делфт технология университеты, Берлаге университеты, Роттердам) лекцияләр укый.

Өч көн буе барган лекцияләрне күп кенә магистратура һәм бакалавриат студентлары, укытучылар, галимнәр, белгечләр һәм шәһәр идарәсе өлкәсендә эшләүчеләр тыңлады.

Соңгы лекция бүген, ягъни 21 ноябрь көнне, «The Haunting Presence of Urban Vampires» темасына багышланачак. Ул 16.00 сәгатьтә Кремль урамы, 6/20 адресы буенча урнашкан бинада, 204 аудиториядә узачак.



Влад Михневский фотосы

Халыкара телевидение көне

# Painting Тележурналистикада – егетләр!

Әңгәмәдәш **Динара МИННЕКАЕВА**

Уку йортыбыз елдан-ел камилләшә. Яңа юнәлешләр билгеләнә, яңа белгечлекләр ачыла. Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты базасында ачылган «Телевещание һәм телепроизводство» кафедрасы тележурналистлар әзерли башлады. Аның эшчәнлеге белән якыннан танышу өчен, кафедра җитәкчесе – доцент, тарих фәннәре докторы Резедә Вәгыйзь кызы Даутова белән сөйләштек.

**– Резедә Вәгыйзовна, кафедра эшчәнлеге белән якынракрак таныштырып китсәгез иде??**

- Безнең кафедраны әле бала дип кенә әйтергә мөмкин. Ул бу уку елының сентябрендә генә ачылды. Ләкин ул буш урында барлыкка килмәде. Хәзер дә һәм күп еллар элек тә Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтында электрон гаммәви матбугат чараларының теориясе һәм практикасы кафедрасы тележурналистлар әзерли иде. Безгә бу кафедрадан зур методологик мирас калды, телевизион дисциплиналарны укыткан укытучылар яңа кафедрага күчте.



Влад Михневский фотосы

**- Димәк, сез быел абитуриентлар кабул иттегез?**

- Әйе, без алардан бик канәгать. Алар бик максатчан, кушкан эшне җиренә җиткереп башкара торган, иҗади студентлар. Кафедрага кабул ителгәннәрнең яртысы – егетләр, мондый хәлнең күптән булганы юк иде инде.

**- Яңа кафедра студентлар өчен нинди мөмкинлекләр тудыра?**

- Беренче чиратта, кафедраның университет телеүзәге базасында эшләве зур уңайлык тудыра, чөнки биредә теорияне гамәлгә ашырып була. Булачак тележурналистлар, чын мәгънәсендә, телевидение эшчәнлегенә «чума». Алар журналистика сәнгатен өйрәнеп кенә калмый, ә операторлык, иң заманча җиһазлар белән монтаж ясау, көндәлек университет яңалыкларын әзерләү һәм башка телепроектларны тормышка ашыруда катнаша. «UNIVERSMOTRI.RU» каналын да исәпкә алсак, студент-тележурналист үзенең карьерасын беренче курстан ук башлый ала.



**-Рустелле тележурналистлар гына әзерлисезме?**

- Әйе, әлегә рус телле тележурналистлар гына әзерлибез. Ләкин шул ук вакытта безнең кафедрада татар журналистикасына укырга кергән студентлар да шөгыльләнә. Дөрес, әлегә ул төркем бик кечкенә. Ләкин без алар белән дә бик ярап эшлибез. Киләчәктә әле инглиз телендә магистратура ачу да планлаштырыла. Әгәр инде без халыкара белем бирү пространствосына эләгергә, чит илләрдән укучылар кабул итәргә телибез икән, һичшиксез, бу планнарны тормышка ашырырга тиеш булачакбыз.

**- Сезнең булачак студентларыгыз нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

- Күптән түгел генә телевидение хезмәткәрләре, студентлар һәм укытучылар катнашында шушы темага багышланган очрашу узды. Бик күп төрле фикерләрдән соң, шундый нәтиҗәгә килдек: журналистиканың киләчәге безнең нинди студентларны укырга кабул итүебездән тора. Алар очраклы гына укучылар булырга тиеш түгел. Булачак журналистлар сайлаган һөнәренә тугры кала торган, шәһәребездә, республикада, илдәге яңалыклардан хәбәрдар, киң карашлы һәм иҗади булырга тиеш.

**- Сез республика күләмендәге телевидениеләр белән хезмәттәшлек итәсезме?**

- Моннан башка тележурналистлар әзерләүне күз алдына китерү авыр. Студентларның күп өлеше җәйге практиканы «Яңа Гасыр», «Татарстан», « KZN», «Эфир» телеканалларында уза. Болар - безне эш белән тәэмин итүче төп база.

**- Сез телевидениенең киләчәген ничек күрәсез?**

- Аның тагын да технологик булачагы көн кебек ачык. Һәм ул тележурналистлар һәм башка телевизион белгечләргә карата булган таләпләрне арттырачак. Контент мәсьәләсенә килгәндә, телевидение җәмгыять мәнфәгатьләренә якынаер, күңел ачуга гына кайтып калмыйча, интеллектуаль һәм рухи якларны да яктыртыр дип ышанасы килә.

**- Хезмәттәшләрегез һәм студентларыгызга нинди теләкләрегез бар?**

- Һәммәсен дә Телевидение көне белән тәбрик итәм. Кызыклы темалар һәм үзенчәлекле ракурсларның күп булуын телим. Иҗат тәмен ешрак татып карарга язсын.

# Үсеш юлында

21 ноябрь – Халыкара телевидение көне. Бу дата 1998 елдан бирле БМО Генераль Ассамблеясе тәкъдиме белән билгеләп үтелә.

Бүген интернет аша мәгълүмат алу киң таралган булса да, телевидение иң популяр гаммәви мәгълүмат чарасы булып кала бирә. Тарих сәхифәләрен барласак, телевизор барлыкка килү 1933 елга карый. Бу вакытта чыгышы белән Россиядән булган Америка инженеры Владимир Зворыкин катодлы торба уйлап таба. Бу җайланма әле бүген дә күп кенә төр телевизорларның төп өлеше булып тора. Зворыкинның бу ачышы нәтиҗәсендә инде 1936 елда ук Англия, Алманиядә, ә 1941 елдан АКШта беренче регуляр телетапшырулар эшли башлый.

Бездә исә телевидение узган гасырның 50 елларында барлыкка килә. 1959 елның 1 ноябрендә Әминә Сафиуллина һәм Айрат Арсланов эфирга чыгып, тамашачыларны татарча сәламли. Эфирга чыгулар аңарчы тәҗрибә рәвешендә генә булса, рәсми телевидение тарихы шушы датадан башлана. Хәзерге заманны телевизордан башка күз алдына китерү кыен, әлбәттә. Университетыбызның да үз студентлар телевидениесе бар. «UNIVERSMOTRI.RU» бүген үзенең үсеш-үзгәреш чорын кичерә.






Влад Михневский фотолары

UNIVERSMOTRI.RU – студентларның тәүлек буе эшли торган интернет телеканалы. Университет студентлар телевидениесе иң заманча һөнәри телевизион җиһазлар һәм Россиядәге булачак журналист-телевизиончылар практикасының иң алдынгы базасы белән тәэмин ителгән.

Студентлар – булачак журналистлар – һөнәрләре өлкәсендә теория белән практиканы белән бергә алып бару мөмкинлегенә ия. Студентларның яңалыклар тапшыруы турыдан-туры эфирда атнага 5 тапкыр чыгып килә. Студент-корреспондентлар видеоны үзләре монтажлый һәм сценарийлар яза. UNIVERSMOTRI.RUның җитештерү бүлеге интернет буенча турыдан-туры эфирны студиядән дә, чара булган урыннан да алып бара.

Университет телекомпаниясе виртуаль дизайнлы ике телестудия белән җиһазландырылган. Аның берсендә эфирга яңалыклар турыдан-туры чыгарылса, икенчесендә төрледән-төрле тапшырулар әзерләнә.

Һәртөрле чаралар: концертлар, фестивальләр, КВНнар студентлар телеканалының туры эфирында күрсәтелә. Әйтик, беренче курс студентлары өчен әзерләнгән концертлар туры эфирда трансляцияләнде. Шул ук вакытта студентлар, сайтка кереп, ошаткан номерлары өчен тавыш бирү мөмкинлегенә ия булды. Шул рәвешле тамашачылар мәхәббәтен яулаган номерлар билгеләнде.

Моннан бер ел элек ике атнага бер тапкыр инглиз һәм кытай телләрендә дә хәбәри чыгарылышлар әзерләнә башлады.

Безгә язалар

Үткән атнада «Күп мәдәниятле дөньяда ислам» исемле милләтара фәнни конференциягә катнашыр өчен, кабат Казанга юл тоттым.

# Тагын очрашканга кадәр, Казан!



**Себастьян ЦВИКЛИНСКИ,** фәлсәфә фәннәре докторы, Берлинның Азат Университеты (Германия) Тюркология институтының штаттан тыш гыйльми хәзмәткәре

Казан федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтының Төбәк һәм исламны өйрәнү кафедрасы тарафыннан үткәрелгән чарада Рәсәйнең төрле төбәкләре, Үзбәкстан, Украина, АКШ, Франция, Германия, Голландия, Австрия, Норвегия галимнәре дә катнашты. Бу конференциянең мөһим бер үзенчәлеге бар иде: ул рус һәм инглиз телләрендә үткәрелде.

АКШ һәм Европаның Көнбатыш илләрендәге рус телен һич тә белмәгән галимнәр Рәсәй мөселманнарын түгел, ә үз илләрендәге ислам дине вәкилләренең тарихы һәм хәзерге халәтен өйрәнү белән шөгыльләнәләр. Шунысын әйтергә кирәк: монда килгән һәркем үзенә файда алды. Көнбатыштан килгән һәм Рәсәйдәге исламны өйрәнмәгән галимнәр, аз булса да татарлар һәм Кавказдагы мөселманнар турында күзаллау булдырдылар. Конференциядә рус һәм татар телле катнашучылар исә, АКШтагы суфичылыкның тарихи үсешенә багышланган чыгышлар ярдәмендә, Көнбатыш мөселманнарының тормышы турында беркадәр мәгълүмат алдылар. Чарада катнашучыларның бер өлеше, минем кебек Рәсәй мөселманнары һәм татарларын өйрәнүче Көнбатыш яки Урта Европа галимнәре өчен дә, мондый төр чаралар бик кызыклы.

Казан шәһәре, аның төп университеты һәм татарлар белән мин инде күптән таныш. Бу юлы Казанга килүем алтынчы тапкыр булды. Беренче визитым 1994 елга туры килгән иде. Казанга берничә тапкыр килгән кеше буларак, шуны әйтә алам: Универсиада уңаеннан шәһәрдә булган үзгәрешләр күзгә ташланып, җанны сөендереп тора. Гомумән әйткәндә, Казан шәһәре минем өчен күпьяклы булуы белән кызыклы. Биредә төрле милләт вәкилләре: татар һәм рус, яһүдләр һәм чувашлар һ.б. дус-тату яшиләр, шул ук вакытта Урта Азия вәкилләре, төрекләр дә, җайлашып, үз бизнесларын үстереп яталар.

Әлеге гомуми тәэсирләрдән кала, Казан шәһәре минем өчен башка яктан да кызыклы. Тюрколог һәм тарихчы буларак, мин Көнчыгышны өйрәнә торган фәннең тарихына карата битараф түгел. Мондый тема белән кызыксынган кеше өчен, Казаннан кала, дөньяда тагын да отышлырак урын бармы икән? Рәсәйнең Көнчыгыш сәясәтен өйрәнүчеләр өчен, Казан университеты тарихы – менә дигән мөмкинлек. Ә суфичылыкның тарихи үсеше белән шөгыльләнүче галимнәр университет китапханәсенең кулъязмалар бүлегендә мөһим чыганаклар белән таныша ала.

Сүз уңаеннан, өстә әйтеп үтелгән конференциядә кулъязмалар темасының күпъяклылыгын бик яхшы ачып биргән берничә чыгыш минем игътибарымны җәлеп итте. Мисал өчен, Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры Диләрә Миркасыйм кызы Госманованың археографик экспедицияләр турындагы чыгышы күңелемдә уелып калды. Конференцияне оештыручыларга барысы өчен дә тагын бер кат чиксез рәхмәтемне җиткерәм.

● «Иделем акчарлагы – 2013»

# Иҗат акчарлаклары

**Илмира КАМАЕВА,**
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

13-16 ноябрь көннәрендә Казанда «Иделем акчарлагы-2013» яшь язучылар бәйгесенең йомгаклау туры үтте.




Катнашучылар арасында Татарстан, Башкортстан, Свердловск өлкәсенең яшь талантлары бар иде. Оештыручылар белдергәнчә, бәйгегә быел барлыгы 85 эш кабул ителгән. Йомгаклау турына исә шуларның 43е сайлап алынган. Иҗатчылар өч көн буе үзләренең осталыкларын сынадылар, башкалар белән тәҗрибә уртаклаштылар, кыскасы, иҗат диңгезендә йөзделәр. Бәйге нәтиҗәләре буенча яшьләрнең әсәрләре тупланган җыентык дөнья күрәчәк.

Яшьләр иҗатына, инде конкурс уздырыла башлаганнан бирле, Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Илсөяр Иксанова, Марат Закир һәм Әлфәт Закирҗановтан торган жюри бәя бирә. Әлеге традициягә быел да тугры калганнар. Татарстан Язучылар берлегендә узган ачылу тантанасында берлек рәисе Рафис Корбан: «Ничек итеп язарга икәнен өйрәтеп булмый. Ләкин өлкән абыйапаларның сүзләрен мыегызга чорнап барсагыз, файдасы тими калмас», – дип, үз киңәшләрен бирде.

Башка еллардан аермалы буларак, конкурс программасында шактый үзгәрешләр бар иде. Традицион рәвештә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында спектакль карау, жюри белән очрашу, психологик тренинглардан тыш, быел үз иҗатыны рекламалау, китап чыгару буенча мастер-класслар, дебатлар, Yummy Music компаниясе вәкилләре, тәрҗемәче Фатих Котлу, галимә Асия Рәхимова, яшь язучылар Йолдыз Миңнуллина, Эльвира Хадиева, Луиза Янсуар белән очрашу, «Тавыш» шигырь сөйләүчеләр бәйгесе һ.б. уздырылды. Бәйгегә яңалыкны талантлы яшьләр тарафыннан оештырылган «Татар Балы» проекты да кертте. Әлеге проектның җитәкчесе – университетыбызның Халыкара мөнәсәбәтләр һәм көнчыгыш телләр институты студенты Энҗе Ибраһимова «Иделем акчарлагы» бәйгесе катнашучыларының иҗади кузаллавын киңәйтүне максат итеп куйган. Шулай ук яшь иҗатчы, КФУны әле генә тәмамлаган Алмаз Мансуров иҗатын тикшерүгә багышланган «Әдәби суд» утырышы да булды. Һәр очрашуда катнашучылар үзләренә яңа белемнәр, кызыклы фикерләр туплады.

Бәйге булгач, аның һәрвакыт җиңүчеләре дә билгеләнә. «Бәйгедә урыннар бирү ул шартлы гына, жиз иләктән иләнеп, йомгаклау турына узган һәрберегез инде җиңүче!» – дип дәртләндерде жюри әгъзалары катнашучыларны. Җиңүчеләр арасында КФУ студентларының күп булуы – икеләтә матур күренеш.

Поэзия номинациясендә 1 урынны – Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты студенты Алсу Нургатина, 2 урынны Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты Гөлназ Яппарова алды. Кызыксындыру бүләгенә ГМһСФИ студенты Илүсә Арикеева лаек дип табылды. Проза номинациясендә җиңүчеләр арасында да безнең студентлар бар. 3 урынны ФһМБИ студенты Чулпан Гобәйдуллина яулаcа, кызыксындыру бүләгенә Гөлназ Яппарова һәм Алсу Нургатина ия булды. Чулпан драматургия номинациясендә дә 2 урынга лаек дип табылды. Балалар әдәбияты номинациясендә 2 урынны ФһМБИ студенты Айгөл Абдрахманова, кызыксындыру бүләген шул ук институттан Светлана Гыйләҗева алды. Оештыручылар һәр катнашучыга бәйге сертификаты, бүләкләр тапшырдылар. Җиңүчеләр исә дипломнар, кубок һәм истәлек бүләкләренә ия булдылар.

Яшь «акчарлаклар» канатларын нығытып, иҗат итәргә яңа көчләр туплап, киләсе очрашуларга кадәр таралыштылар. Бәйге кысаларында галимә Асия Рәхимова белән уздырылган очрашудан аның сүзләре күңелгә кереп калды: «Киңәергә кирәк! Әлеге сүзләрне һәркем үзенчә шәрехли, дуслларым». Чыннан да, адәм баласы һәрвакыт үсештә булырга, үз алдына максатлар куеп, шул максатка ирешү өстендә эшләргә тиеш. «Иделем акчарлагы» кебек бәйге иҗатчылар өчен чын мәгънәсендә киң мәйдан, үсеш юлы булып тора.

Гөлназ ЯППАРОВА иҗаты



## Кояшка

*Кояшка үрелгән сузылган куллардан*
*Сихерле көч тама бу җиргә.*
*Талпына-талпына очарга*
*теләк бар:*
*Аяклар астында нык эргә.*
*Киң сахра буйлатып чәчелгән*
*уй-теләк –*
*Кояшка, кояшка, кояшка!..*
*Күтәрә алмаслык ташкыннар*
*ишелмәс*
*Ходайдан бирелгән бер башка.*
*Талпынып очканда, Галәмнең*
*киңлеге*
*Җыр көйләр азатлык хакында.*
*Кояшка үрелү ни тора соң безгә,*
*Хыяллар, уй-теләк хакына?..*
*Кояшка, кояшка...*

## Хәтер сандыгы

(Археографик экспедицияләр истәлеге)

*Теткәләнгән сары капчык белән*
*Нафталинлы сандык төбендә,*
*Капка төбен саклап утыручы*
*Сиксән яшьлек карчык өендә*
*Яшеренеп ята икән Хәтер.*

*Ул бик күптән инде саргайган...*
*Бик кадерле дәверләре кайчан*
*Үтеп китте икән?..*
*Моң сарган...*

*Хәтерләргә тели сыман Хәтер*
*Кем башыннан Хәтәр узганын.*
*Йөзлекләрне ваклап яткан сандык*
*Менә бүген тәү кат кузгалган:*
*Җир җимертеп йөргән җиһангирлар,*
*Каһан иле,*
*әһле Ислам кауме...*
*Меңәрләгән гаскәр илә килеп,*
*Теләгәне илме,*
*әллә ямы?*

*Аксакаллар сүзе акка кара:*
*«Байлык – көчтә,*
*ә матурлык – яшьлек.*
*Тезгененнән нык тотарга тырыш –*
*Бу васыять сиңа,*
*Кешелек!»*

*...Нафталинлы Хәтер сандыгының*
*Ак яулыклы карчык өендә*
*Актарырга туры килде төбен*
*Сиплэтелгән йортның түрендә.*

## Сөю

*Җылы яңгыр дымын тарта*
*Таң алдыннан салкын офык.*
*Кайнар сулыш тыны чит-ят,*
*Берәү атлап китте шак-шок.*

*Агачларга кунган сары*
*Үз итәрә тели җирне.*
*Күзләрендә яңгыр дымы*
*Карашлары эзли күкне.*

*Җылы нурның бер балкышы*
*Юатырдай төсле Җирне.*
*Вәгъдә сүзләр хәзер артык...*
*«Мин яратам, җаным, сине!»*

● Халәт

# Куркып яшәмик

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Белгәнебезчә, куянның беренчел асыл сыйфаты булып куркаклыгы санала. Ләкин бу сыйфат куянга гына түгел, кешеләргә дә хас.



Һәрнәрсәдән шүрләүчеләрне «куян» дип үртәү дә шуннан калгандыр. Безнең һәрберебез үзенчә – куян, чөнки бу тормышта нәрсәдән дә булса куркабыз. Курку – кешенең аерылмас бер өлеше. Кемдер караңгылык, биеклектән, кемдер таракааннардан шүрли. Табигать үзе шулай яраткан. Юкса, инде күптән Җир йөзендә адәм затының эзе дә булмас иде. Ник дигәндә, курку безгә үз-үзебезне саклап калу өчен кирәк. Әмма фобияләр (ияреп йөрүче куркулар) кайберәүләрнең бөтен тормышын ямьсезли, бертөрле авыруга әйләнә. Кеше күп булган урыннардан, дөнья бетүдән курку – монысы әле ярый, ә менә форфордан ясалган уенчыклар, гап-гадикүбәләкләрдән шүрләүчеләрне бөтенләй аңлап булмый кебек. Боларның нигезендә, куркудан бигрәк, аның белән көрәшә алмау ята. Кемдер үзенең курыкканлыгын аңлап елмаеп кына куйса, икенчеләр өчен үз өендә ялгыз калу да зур бер җәзага тиң.

Галимнәр исәпләвенчә, Җир йөзендәге һәр дүрт кешенең берсе нәрсәдән булса да курка. Һәм аларның күбесе югары интеллект дәрәҗәсенә ия. Белем букчасы тулылану белән, фобияләр саны да арта икән. Әйтик, соңгы вакытларда аның космикофобия (космик күренешләрдән курку), киберфобия (компьютер белән эшләүдән курку), прософобия (алга китештән курку) кебек төрләре барлыкка килгән. Реклама карап, кайберәүләр верминофобия (микроблардан шүрләү), фалакрофобия (пеләшләнүдән шүрләү), обезофобия (симерүдән шүрләү) белән интегә. Иң еш очраучы метрога төшүдән курку, авылдан килүчеләргә түгел, ә нәкъ менә шәһәрдә яшәүчеләргә хас икән.

Күпләр үзенең курыкканлыгын яшереп, аннан оялып йөри. Шуңа күрә психологларның да бу өлкәдә белеме җитәрлек түгел. Шүрләүдән котылу өчен, курыккан әйберeңне күз алдына китереп, аны аң белән тоеп карарга киңәш итәлә. Үз-үзеңә карата ышанычны арттыру да ярдәм итми калмас. Әлбәттә, биеклектән куркучыларга парашюттан сикерү мөмкин түгел хәл булып тоелыр. Әмма билгеле бер әзерлек үтеп, сикереп карасаң, акрофобиядән котылырга мөмкин.

Дөнья матур, дөнья киң: куркып яшәмик, дуслар! Үз-үзенә шаярып, шул ук вакытта ышанып караучы, якыннарының ярдәмен тоеп яши белүче батыр затлар булыйк!

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.